КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 август г.Казань № 983

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат үзәге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче; 2013 ел, 14 февраль, 103 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 936 нчы; 2014 ел, 9 июль, 479 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 686 нчы; 2017 ел, 1 ноябрь, 830 нчы; 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2019 ел, 23 июль, 618 нче; 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче; 2021 ел, 27 март, 177 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында каралган кредит оешмасының мәгълүмат системасы.»;

10 пунктта татар текстында «башка мәгълүмат системалары операторлары» сүзләреннән соң «, әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында каралган кредит оешмасы» сүзләрен өстәргә;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үзәк операторы һәм әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында каралган кредит оешмасы арасында мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибе әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән килешү нигезендә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16. Кредит оешмасына караган мәгълүмат системасы белән Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталының һәм үз-үзеңә хезмәт күрсәтә торган мәгълүмат терминалларының түләү шлюзы (алга таба – түләү шлюзы) арасында мәгълүмати-технологик хезмәттәшлекне үстерүне һәм аның эшләвен тәэмин итү Үзәк операторы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләү шлюзы белән кредит оешмасына караган мәгълүмат системасының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген үстерүне һәм аның эшләвен тәэмин итү хокукына конкурс (алга таба – конкурс) йомгаклары буенча җиңүче дип танылган кредит оешмасы белән Үзәк операторы тарафыннан төзелә торган килешү нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итмичә, Үзәк операторының техник таләпләре нигезендә кредит оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин